РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

«_12_» __ноябрь_ 2024 ел №_274__

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге вәкиллекле органының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрне Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында тәкъдимен кабул итәргә:

- җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслау;

- җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетына:

- Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне кушымта нигезендә типлаштырылган форма нигезендә тапшыру турында килешү төзергә;

- әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турында Татарстан

Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тапшырырга.

3. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнары үз компетенцияләре чикләрендә әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән Килешүне гамәлгә ашыру өчен норматив һәм норматив булмаган хокукый актлар чыгарырга хокуклы дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов